Татарстан Республикасы Спас муниципальрайонының
Чәчәкле авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 63 29.03.2022

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советының 2021 елның 24енче сентябрендәге 42 карары белән расланган Чәчәкле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (2021 елның 07 декабрендәге 54 номерлы үзгәрешләр белән )

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советының 2021 елның 24енче сентябрендәге 42номерлы карары белән расланган Чәчәкле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (2021 елның 07 енче декабрендәге 54 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы абзац өстәргә:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

б) унынчы - унөченче абзацларны унберенче - ундүртенче абзацлар дип санарга.

1.2. 20 статьяның 2 өлешендә «җирлек йөкләмәләре» сүзләрен «тиешле ел ахырына файдаланылмаган бюджет кредитының инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән калдыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Чәчәкле авыл җирлеге башлыгы: Р.Р. Фәисханов